# Безгә 1 яшь!


# Нәсыйхәт

җомга
24
февраль
2012 №13

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


## ЗУР ҮС, “НӘСЫЙХӘТ”!

**Хөрмәтле газета укучылар! Иң кадерле, изге хисләребезне, теләкләребезне чагылдырган “Нәсыйхәт” газетасы бер яшен тутырды. Бер ел элек, нәкъ шушы көннәрдә, төгәлрәк 25 февральдә, газетабызның беренче саны дөнья күргән иде.**

–Зур үс!

Шул сүзләр белән сөйгән баланы әти-әнисе, туганнары үбәләр, күкрәкләренә кысып, аркасын сыйпыйлар.

“Нәсыйхәт” әле кечкенә, аңарга нибары 1 яшь. Шиксез һәр бәләкәчкә хас булган кимчелекләре дә юк түгелдер, үзенә күрә сабыйлыгы да, балачагалыгы да бардыр... Шулай да без дә бүген газетабызны тәбриклибез, саулык, бәхетле көннәр телибез!

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, яше кече булуына карамастан, газетаның юлы, төрле вакыйгаларга, төрле кичерешләргә бай. Авырлыклары да булмады түгел: журналистларны табарга, типография проблемаларын чишәргә, әз булса да эш хакы түләргә кирәк. Күз курка, куллар эшли. Алай да күпме энергияне алгандыр беренче адымнар... Әмма, авырлыкларга бирешмичә, бөтенләй сулып бетәргә торган чакларда да аягына баса белде “Нәсыйхәт”. Бу, әлбәттә, газета коллективының хезмәте. Алар үзләренең объективлыгы, гаделлеге, җитешсезлекләргә битараф булмаулары белән аерылып торалар.

Без уңышлы финишка әзәрүче активистларыбыз белән горурлана алабыз. Баш мөхәррир Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин, мөхәррир урынбасары Эльвира Хәбибуллина, җаваплы сәркатип Алсу ханым Спиридонова, дизайн һәм верстка өчен җаваплы Фирая Мингалиева, хәбәрчеләребез Әлфира Хаҗиева, Рәйсә Рәхимҗанова, Мөнирә Нәбиуллина, Фатыйма Салихова, Сабирҗан Әхмәтҗанов, Ленар Хамматов, Венера Яруллина, Лена Муратова, Сөмбел Шәрифуллина – “Нәсыйхәт”нең чишмә башында торучы шәхесләр. Уйлап карасаң, нинди сәләтле, оста шагыйрьләребез, дини мәкалә осталары “яшеренеп” ятканнар икән безнең районыбызда! Газетаның абруе көннән-көн үсә, дәрәҗәсе күтәрелә бара. Кешенең дөньяга карашын, идеалларын формалаштыруда зур тырышлык, теләк, үҗәтлек, нык ихтыяр көче сарыф ителә. Шуңа күрә газетаны яратып укучыларның саны арта бара. Иң зур шатлыгыбыз – мәдрәсәдә укучылары да бик матур, әчтәлекле шигырьләр һәм мәкаләләр язып газетабызда бастыралар. Газетаның тарихи миссиясе зур. Чөнки ул халкыбызның бай рухи традицияләрен онытмыйча яши, сайлаган кыйбласыннан тайпылмый. Газета төрле темаларны колачлап, һәр өлкәгә тиешенчә игътибар бирергә омтыла. Монда республикабыздагы дини яңалыклар, яшьләр, сәламәтлек, спорт, һәм гомумән җәмгыятьтәге күп проблемалар колачлана. Телебезне, гореф-гадәтләребезне, мәдәниятебезне саклап килүдә газетаның роле аеруча зур. Газета ярдәмендә күренекле имамнарыбызны, атаклы шәхесләребезне, сугыш ветераннарын беләбез, истә тотабыз.



**Газетаның тарихи миссиясе зур. Чөнки ул халкыбызның бай рухи традицияләрен онытмыйча яши, сайлаган кыйбласыннан тайпылмый.**

Газетаның тоткан кыйбласы киң җәмәгатьчелек бурычлары белән уртак. Җәмгыятебездә җинаятьчелек, наркомания, әдәпсезлек һәм әхлаксызлык арта барган чорда газетабыз битендәге матур әдәби тел аша, хикмәтле сүзләр көче ярдәмендә кешеләрнең аңын, рухын сәламәтләндерү эше алып барыла.

“Нәсыйхәт” газетасы вакыт белән бергә атларга тырыша. Тормыш вакыйгалары белән таныштырса, үзенең киңәшләрен дә бирергә онытмый. Газета битләрендә гыйбрәтле хәлләр белән танышу белән беррәттән, үрнәк шәхесләрнең язмышларын чагылдырган язмаларны да укырга мөмкин.

Газетаның һәр санында дип әйтерлек никах, ата-ана нәсыйхәте, әхлак мәсьәләләре яктыртыла, “гаилә институтлары” эшчәнлеген яхшырту, яшь буынны яңа шартларда тәрбияләү юнәлешендә каләм тибрәтелә. Газета гаделлеккә, мәрхәмәтлелеккә омтыла, аңа иҗади эзләнү хас. “Нәсыйхәт” район газеталары белән дә хезмәттәшлек итә, үз укучылары белән даими элемтәдә тора. Районыбызның төрле төбәкләрендә яшәүче кардәшләребезнең тормышы, алардагы яңалыклар белән һәрдаим кызыксынып, укучыларын таныштырып барырга тырыша.

“Нәсыйхәт”! Сиңа яхшы һәм бай тормыш телибез. Ешрак кил безнең өйләребезгә. Ә без исә “Нәсыйхәт”нең һәр санына җан өрүче коллективыбыз, биргән вәгъдәләргә тугры калып, аны тагын да кызыклырак, файдалырак итәргә омтылырбыз. Аллаһы боерса, киләсе елда да бар йөрәк җылысын, күз нурларын салып сезнең өчен эшләрбез, хөрмәтле укучыларыбыз!

## Яңалыклар

### МӘДРӘСӘДӘ АЧЫК ДӘРЕС

20нче мартта Мамадыш мәдрәсәсендә Коръән тәфсире буенча ачык дәрес уздыру планлаштырыла. Анда башка дини уку йортларыннан укытучылар һәм методистлар килер дип көтелә. Мондый төрдәге ачык дәресләр үткәрү мөгаллимнәр арасында тәҗрибә алышуга җирлек тудырачак.

### КОРЪӘН УКУ БӘЙГЕСЕ

Мәдрәсәдә Коръән уку бәйгесен үткәрүгә әзерлек бара. Әлеге чарада мәдрәсә шәкертләре катнашачак. Шулай ук, бүгенге көндә авылларда да ярышның беренче этабы бара. Район күләмендә узачак бәйгенең йомгаклау этабына хакимият вәкилләре дә, шулай ук Татарстан Җөмһүрияте Дини я нәзарәтеннән дә кунаклар көтелә.

### ҖОМГА НАМАЗЛАРЫНДА

Мәдрәсә мөгаллимнәре тарафыннан авыл мәчетләрендә җомга намазлары укытыла. Алар катнашында Арташ, Кече Кирмән, Түбән Ушмы, Олыяз авылларында җомга намазлары үткәрелде. Чираттагы җомганы Урта Кирмән авылы мәчетендә Габдрахман хәзрәт уздырды.

### ТАНЫШТЫРАБЫЗ, ЧАКЫРАБЫЗ

Мамадыш мәдрәсәсе укытучылары район авыллары буенча йөрүне дәвам итә. Бу эшнең максаты районнарыбызда белемле, тиешле дәрәҗәле имамнар, Ислам нигезләренә өйрәтүче укытучылар һәм башка дин белгечләрен булдыру. Шул исәптән Мамадыш мәдрәсәсе вәкилләре тарафыннан район авыллары, мәктәпләре һәм мәчетләре буенча таныштыру-чакыру эшләре алып барыла. Бу эшләрнең максаты – мәктәп балаларын Ислам белән таныштыру һәм шулай ук мәдрәсәгә студентлар әзерләү булып тора.

### ИҢ ЯХШЫ ШӘКЕРТ

Мамадыш мәдрәсәсе “Иң яхшы шәкерт” бәйгесе игълан иткән иде. Әлеге бәйгенең максаты: дини гыйлем бирүне көчәйтү, популярлаштыру, студентларның белем сыйфатын яхшырту, укытучыларның белгечлек дәрәҗәсен арттыру, студентларны төрле иҗтимагый чараларда катнашуга кызыктыру иде. Җиңүче булып Яшел Тау авылы шәкерте Миннеханов Дәнис табылды.

### ОСТАЛАРДАН ӨЙРӘНӘБЕЗ

Мәдрәсәдә уку-укыту эшләре буенча җаваплы Ранил хәзрәт Талипов икенче санлы лицейда уздырылган “Ел укытучысы” дип исемләнгән рәсми чараның шаһите булды. Укыту эшләрендә кулланыла торган яңа алымнар белән танышты, төрле презентацияләрне күзәтеп бу өлкәдә тәҗрибә туплады.

### КАЛӘМНӘРЕГЕЗНЕ ЧАРЛАГЫЗ!

“Нәсыйхәт” газетасы ислам тематикасына багышланган “Иң яхшы дини мәкалә” һәм “Иң яхшы дини шигырь” дип аталган конкурс игълан итә. Җиңүчеләрне истәлекле бүләкләр көтә. Һәр катнашучының иҗади җимешләре безнең газетабызда бастырылачак. Мәкаләләр һәм шигырьләр 30 нчы апрельга кадәр кабул ителәләр. Аларны мәдрәсә электрон почтасына яки хат рәвешендә җибәрүегез мөмкин.

**Безнең адрес: М. Җәлил ур. 8/28 эл. почта: mamadysh-medrese@mail.ru**

# Мәрхәмәтебез белән булыйк бәхетле



**“Кош–очар өчен, кеше бәхет өчен яратылган”–диләр безнең татар халкында.**

Безнең һәркайсыбызның бәхетле буласы килә. Бәхетне һәркем үзенчә аңлый. Тамагы тук, өс -башы бөтен булса, кеше үзен бәхетле итеп сизә. Ә кемнәрнең изгелек кылып, мәрхәмәтле булып күңелендә бәхет хисләрен тойганы бар?

Без әти-әниләргә, әбибабайларга, карт-карчыкларга, күрше-күләннәргә, ятимнәргә игътибарлы була беләбезме? Ә нинди игелекле эшләр эшләгәнебез бар? Халкыбызда әүвәл-әүвәлдән ятимнәргә, кулы-аягы гарипләргә, язмыш кимсеткән, табигать кыерсыткан кешеләргә карата аерым бер караш яшәп килгән. Аларны кызганганнар, хәлләренә кергәннәр, кулларыннан килгәнчә ярдәм күрсәткәннәр. Аларга карап: “Биргәненә шөкер, акылым тулы, зиһенем бөтен”,–дигәннәр, гыйбрәт алганнар, тәүбә иткәннәр. Мондый кешеләргә шәфкатьле булганнар. Бүгенге катлаулы заманда шәфкатьле булу бигрәк тә кирәк. Ана назын, ата сөюен күрмәгән күпме сабый, ятим бар. Инвалидлар, картлар йортлары күбәю дә безгә, яшь буынга, шул турыда чаң суга. Шәфкатьле булу – барлык күркәм гадәтләрнең башы, әдәплелекнең нигезе. Чөнки бары тик шәфкатьле кеше генә күркәм гадәтләргә ия, бәхетле, тәүфыйклы, мәрхәмәтле, игътибарлы, кешелекле була ала. Газета-журналларда шәфкатьлелек турында мәкаләләр тәкъдим ителә, аларда кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә аңлатма бирелә. Без аларны укыйбыз, фикер алышабыз, яманнан яхшыны аерып, шәфкатьле булырга өйрәнәбез.

Бүгенге көндә янәшәбездә, золым күргән, ачлык чиккән кешеләрнең барлыгы хакында һәркемнең хәбәре бар. Газета һәм телевизорда бу мохтаҗлар хәлен ачыклаучы хәбәрләр белән еш кына очрашабыз. Күпчелегебезнең бу кешеләрнең мескен хәлдә булганнарын күреп, күңелләребездә аларга карата кызгану хисе уяныр. Әмма аларны коткару өчен нинди дә булса чаралар булдырабызмы? Киресенчә, кайвакыт бу фаҗигаләр каршысында җаваплылык бездә түгел, бәлки башка берәү җаваплы сыман тоеп, үзебезне алдалыйбыз түгелме? Араларыбызда хәтта, берәр нәрсә булдыру кирәклеге хакында уйланучылар булса да, “үзем генә ялгыз мин бер нәрсә дә булдыра алмам” фикеренә бирелерләр.

**(Дәвамы 3нче биттә)**

**(Ахыры. Башы 2нче биттә).**

Чынлыкта исә, бу бик хаталы төшенчә. Чөнки һәрберебез көчебездән килгәнчә ярдәм кулы сузсак, җир йөзендә мохтаҗларның саннары күпкә кимер иде. Сүз дә юк һәрбер кеше акча, мал белән ярдәм итә алмаска мөмкин, әммА җылы сүз белән, игътибар белән, киңәш белән һәрберебез ярдәм итә алабыз.

Хакыйкатьтә, үзен мөселман дип санаган һәр кеше Раббысына тәвәккәллек итер, аңа Аллаһ ризалыгы өчен хәерле эшләр башкаруда комачаулаучы бер нәрсә дә киртә була алмас. Ул һәрдаим Аллаһ юлында хезмәт итеп, зур игътибар һәм кайгырту белән, Аллаһның ризалыгын, рәхмәтен алыр өчен һәм мөселманнар өчен хәзерләнгән җәннәткә лаек бер кеше булыр өчен тырышлык күрсәтер.

Ул бер хәерле эшне башкарып, шунда ук башка бер хәерле эшкә тотыныр, мөмкин кадәр тиз һәм күп яклы хезмәтләр башкарыр. Аллаһка булган бәйлелеген чагылдыручы иң хәерле хезмәтләр үтәп, җитди тырышлык күрсәтер. Раббыбыз бу хакта болай ди: “Бер хәерле эштән бушансаң, икенче хәерле эшне эшләргә тырыш. Һәм Раббыңның рәхмәтенә кызык, Раббыңа таба ашык, һәм һәрвакыт Ул риза булачак хәерле эшләр белән мәшгуль бул!” (Инширах: 7-8)

Ул гына да түгел, Аллаһ “Бәкара” сүрәсенең 148 нче аятендә мөэминнәргә “хәерле гамәлләрдә ярышуларын” әмер итә. Шуңа күрә мөселман кеше һәрвакыт нинди дә булса әҗер казану өчен тырышыр, вазыйфаны башкару мөмкинчелеген урап үтү, я башка берәрсенә йөкләү урынына, кичектермәстән чыккан форсатны кулланыр. Башкарган хезмәтләре өчен, һич кемнән дә рәхмәт сүзләрен ишетүне өмет итмәс. Киресенчә, Аллаһның ризалыгын һәм рәхмәтен казануга һәм исән чакта, мөмкин булганча әҗерләр туплауга үзенең мохтаҗ икәнен аңлап, канәгатьлек белән ислам юлында тырышлык күрсәтер. Бу хакта Раббыбыз болай ди:

“Дәхи алар Аллаһ ризасы өчен мескеннәргә, ятимнәргә һәм тоткында булган мөселманнарга аш һәм сәдака бирерләр. Алар әйтерләр: “Без сезне фәкать Аллаһ ризалыгы өчен генә ашатабыз, без сездән өмет итмибез, каршысына безгә бер изгелек итүегезне һәм дога кылыгыз, дип тә әйтмибез.Чөнки без Раббыбыздан куркабыз катылыгы белән йөзләрне чытыкландыручы кыямәт көненнән”, – дип...

Безнең күңелебездә шундый сорау туарга мөмкин: ә нигә бу кешеләргә Аллаһ Тәгалә ярдәм итми, ул бит барыбызны да туендыручы?! Әлбәттә, Раббыбызга колларын нигъмәтле итү берни түгел. Әмма ул безне шул рәвешле сыный. Ярлыларны ачлык белән булса, безнең ни дәрәҗәдә ярдәмчел, изге күңелле булуыбызны тикшереп карый.

Хәйрия, игелеклелек, мәрхәмәтлелек, ярдәм, күңел күрү... Мондый эшләр турында кычкырып сөйләү дә, газета-журналларга язу да килешми кебек. Яшертен эшләнгән ярдәмнең бәясе күпкә югарырак. Ләкин игелеклелек яшәеш нормасы булган җәмгыятьтә генә бу шулайдыр. Ә бүген исә, җәмгыятебездә тискәре күренешләр таралган мәлдә, күркәм изгелек үрнәкләре хакында сөйләү бик кирәкле эш икәненә төшенәсең.

Бу кемнедер битарафлыктан уята, кемгәдер тәвәккәллек өсти.

Мамадыш мәдрәсәсе дә көченнән килгәнчә мохтаҗларга, ятимнәргә, авыр гаиләдәге балаларга ярдәм итәргә тырыша. Әле күптән түгел “Бергәләп изгелек кылыйк” дип исемләнгән декада үткәрде. Мәдрәсәдә бу чара җәмәгатьчелекне мохтаҗлар проблемасына җәлеп итү, гарипләр хәзерге заман җәмгыятендә яшәргә сәләтле түгел дигән фикерне юкка чыгару максатыннан үткән иде. Декада барышында мөмкинлекләре чикле булган кешеләрнең иң мохтаҗларына ярдәм ителде, ризык таратылды.

Шулай ук, хәйрия акциясе кысаларында мохтаҗларга һәм гарип кешеләргә ярдәм итү оештырылды. Аларга корбан ите таратылды. Ярдәмгә мохтаҗ булганнар чарадан канәгать калдылар, рәхмәтләрен белдерделәр. Мөмкинлекләре чикле булган кешеләргә ярдәм йөзеннән оештырыла торган марафонда да көче җиткәнчә катнаша мәдрәсә. Әз булса да үз өлешен кертә.

Гошердән җыелган яшелчәләрне һәм бәрәңгене дә авыз итмичә калмадылар мохтаҗлар. Шулай ук ялгыз әбиләргә дә мәдрәсә гошердән өлеш чыгарды.

“Мохтаҗларга ярдәм кулы сузыйк” дип исемләнгән акция кысаларында мәдрәсә тарафыннан кулланышта булган киемнәр дә җыелган иде. Бу киемнәр күп балалы гаиләләргә һәм коррекцияләү торак мәктәбенә бирелде.

Ел саен мәдрәсә сугыш ветераннарын да кунакка чакыра. Аларга ризык табыны әзерли, бүләкләргә дә онытмый. Мамараимовлар гаиләсе дә бүгенге көндә мәдрәсә шефлыгы астында. Бу гаиләгә төрлечә ярдәм күрсәтелә...

Ярдәм сорап кергән кешеләрне дә, мосафирларны да буш кул белән борып чыгарырга тырышмый мәдрәсә, әз булса да ярдәм итмичә калмый.

Сер түгел, бүгенге көндә мәчет-мәдрәсәләр турында төрле фикерләр ишетергә туры килә. Янәсе алар гел сәдакаларга гына өметләнеп яшиләр, үзләре һичбер эш кырмыйлар, кеше хәерен генә ашап ятучылар... Әмма нәрсә генә сөйләмәсеннәр, мәдрәсә үзе мохтаҗ булса да, үзеннән дә мохтаҗракларга ярдәм кулы сузарга тырыша. Шуңа күрә аның үзен дә Аллаһ рәхмәтеннән ташламый, игелекле колларын җибәреп ярдәм итеп тора.


Газиз кардәшләребез! Без дә башкаларга карата юмарт булырга өйрәник, үзебезне тел белән дә, мал-мөлкәт белән дә изгелек кылырга гадәтләндерик! Һәр һөнәр иясе үз эшенең бер өлешен Аллаһ ризалыгы өчен эшләп, изгелек кылса иде. Бу кыска вакытлы тормышыбыз өчен дә көн-төн тир түгәбез бит, ә мәңгелек тормышыбыз турында кайчан кайгырта башларбыз?

Һәрхәлдә, үзебезне өстен тотып, ярлылар яныннан битараф үтеп китмәсәк иде. Сәдака бирә алмасак, киңәш бирик, һичьюгы бу адәм өчен Аллаһка дога кылыйк. Кемнәрдер моны көлке итеп кабул итәрләр, ни хәл итәсең, җәмгыятебез мондый гамәлләрдән шактый ерак шул. Әмма кыямәт көнендә Аллаһның ризалыгын, Мөхәммәд (с.г.в.) нең яклавын алыр өчен тырышкан мөселман өчен бу көлке булмас.




**Рәсемнәрдә: без Урта Кирмән авылында яшәүче Мамараимовлар гаиләсендә көтелгән кунак.**

# МӘКТӘП ҺӘМ ДИН: АРАЛАР ЯКЫНАЯ



**Рәсми карар нигезендә быелгы уку елының IV чирегендә, республикабызның барлык мәктәпләрендәге IV сыйныф укучылары дини мәдәният яисә дөньяви этика нигезләрен өйрәнә башлаячак. Димәк, бу фикер белән хәзер рәсми даирәләр дә килеште, мәктәпләрдә дин тарихы дәресләренең зарурлыгы турында көннән-көн ешрак сөйлиләр. Тик әлегә ничек укытырга, нәрсә укытырга, кем укытырга тиешлеге хакында гына килешеп бетә алмыйлар. Әйе, бу бик четерекле мәсьәлә, баланың җанына, калебенә кагылышлы эш. Монда хаталанырга ярамый. Бәлки укытучылар ике якка да тигез игътибар бирер, әмма балалар дөньясының үз тәртибе. Ул исә президент карарларына да, министр әмерләренә дә буйсынмый. Балалар бу дәресне кабул итә алырлармы? Бүгенге сабыйлар телевизорны, төсле журналлар һәм интернет уеннарын гадәти, мәҗбүри дәресләрдән артыграк күрә. Ә инде яңа предмет өстәлсә, ни булачак? Шуңа күрә тәҗрибә вакытында нәрсә укытырга түгел, ә ничек дәрес бирергә кирәклеген хәл итәргә туры киләчәк. Без, бу мәсьәлә кагылышлы сораулар белән мәдрәсә директоры Габдрахман хәзрәткә мөрәҗәгать иттек.**

**–Габдрахман хәзрәт, соңгы елларда күпдинле һәм күпмилләтле Россия Федерациясе мәктәпләрендә дини дәресләрне укыту мәсьәләсе укытучыларны да, ата-аналарны һәм киң җәмәгатьчелекне дә җитди уйлануларга этәргән иде. Бүгенге көндә бу мәсьәлә нинди юнәлеш алды? Әлегә бу юнәлештә нинди эшләр башкарылды?**

–«Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика» дәресләрен барлык мәктәпләрдә өйрәнә башлау алдыннан 240 мең укучыны һәм 10 мең мәктәпне үз эченә алган 19 төбәктә ике елга исәпләнгән эксперимент үткәрелде һәм ул уңай нәтиҗәләрен бирде. Бу эксперимент Идел буе округыннан Чувашстан, Удмуртия республикаларында һәм Пенза өлкәсендә сынау узды.

**–Башлангыч мәктәпкә кертеләчәк «Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика» дип аталган комплекслы уку курсының эчтәлеге нидә?**

–Әлеге уку курсы алты аерым модульдән тора:
1. Православие мәдәнияте нигезләре 2. Ислам мәдәнияте нигезләре 3. Будда мәдәнияте нигезләре 4. Яһүд мәдәнияте нигезләре 5. Дөньякүләм дин мәдәниятләре нигезләре 6. Дөньяви этика нигезләре

**–Димәк, мәктәпләребездә һәр укучы тәкъдим ителгән алты модульнең берсен сайлап алырга һәм өйрәнергә тиеш?**

–Әйе, диннәр мәдәниятенме, әллә бөтенләй дөньяви этика курсымы – болар барысы да укучылар теләген, ата-аналарның караш-мөнәсәбәтен, укытучы мөмкинлеген исәпкә алып сайланырга тиеш. Укучыларның, әти-әниләрнең ихтыяҗын өйрәнгәннән соң, нинди модульне өйрәтү кирәклеген мәктәп мөстәкыйль төстә үзе хәл итә.

**–IV сыйныфта яңа кертелә торган «Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика» дигән предметның максаты нидән гыйбарәт дип уйлыйсыз?**

– Әлбәттә, иң беренче чиратта укучыларны диннәр мәдәнияте нигезләре белән таныштыру, төрле диннәргә һәм милләтләргә толерант караш булдыру. Әлеге дәресләр белән танышканнан соң балалар дөньядагы рухи кыйммәтләрнең нигезендә диннәр ятканлыгын аңларга, төрле милләтләрнең мәдәнияten һәм гореф-гадәтләрен бәяли белергә, аларны саклап калу кирәклегенә төшенергә тиеш булалар.

**–Рәсми мәгълүматларга караганда, республикабыз мәктәпләрендә «Дөньякүләм дин мәдәниятләре нигезләре»н – 20976, ә «Дөньяви этика нигезләре»н 13948 укучы өйрәнәчәк. Бу мәсьәләгә карашыгыз нинди?**

–Сүз дә юк, мәктәпләрдә бер дин белән генә бәйләнгән дини дәресләрне укытуны башка диндә булган балалар да, ата-аналар да, укытучылар да аңламаячак. Шуңа күрә классны дини яктан аермас өчен «Дөньяви этика нигезләре» яисә «Дөньякүләм дин мәдәниятләре нигезләре» модулен өйрәнү проблеманы уңай хәл итәргә мөмкинлек бирә. Тик шулай да, барлык этик кагыйдәләрнең нигезендә дини нормалар ятса да, мәктәптә турыдан-туры дини мәдәният нигезләрен өйрәнү отышлырак булыр иде. Чөнки республикабызда диннәр мәдәнияте нигезләрен өйрәнергә ихтыяҗ зур һәм аны бүген булмаса, иртәгә канәгатьләндерергә туры киләчәк.

**–Мәктәпләрдә бу яңа предметны укытуның нәтиҗәсе тулаем укытучыдан тора. Бу яңа курсны кем укытырга тиеш соң? Мәчет-мәдрәсәләрдә бу юнәлештә хезмәт башкарырлык укытучылар әзерләү мөмкинме?**

–Дин әһелләре бүген дәүләттән хезмәт хакы алмый. Мәчетләрнең-мәдрәсәләрнең җиренә, утына салым түләргә кирәк. Шуңа күрә дәүләткә динне укытучы мөгаллимнәрне әзерләүне мәчет-мәдрәсәләр үз өстенә ала алмый. Безнең андый матди мөмкинлегебез юк. Бу Мәгариф министрлыгы аша әзерләнергә тиешле кадрлар. Аның өчен махсус программалар язылa. Гомумән алганда бу дәүләтнең бурычы. Һәрхәлдә, яңа предмет буенча дәресләр башланыр алдыннан барлык укытучылар өчен методистлар, галимнәр, дин әһелләре катнашында саллы сөйләшүләр, очрашулар оештыру кирәклеге көн кебек ачык. Бу эшне җайга салган вакытта республика мәгариф системасында тупланган тәҗрибәне дә файдалану кирәк. Мәсәлән, шактый күп еллар Балтач районында – «Әхлак дәресләре», ә кайбер районнарда «Диннәр тарихы» алып барылды. Күренекле дин галиме Р.Фәхреддиннең «Тәрбияле бала» һ.б. китапларын файдалану да кирәк дип саныйм.

**–Дини тәрбияне армиядә бирүгә ничек карыйсыз?**

–Әйтергә кирәк, бирелә ихтыяҗ зуррак та әле. Чөнки бүгенге көндә дөньядагы өч армиядә генә рәсми рәвештә дин әһелләре эшләми икән – Кытай, Төньяк Корея һәм Россия. Рәсми мәгълүматларга караганда бу юлы руханиларны читтән чакырмакчылар. Аларның бернинди дә хәрби бурычы булмаячак.

**–Сезнең фикерегезчә бала тәрбиясенең нигезе нидә?**

–Алтыннан бәһале, оҗмах нигъмәтләреннән кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык вә ахирәттә йөзгә аклык китерер. Ләкин яхшы булам, дип кенә, яхшы булып булмый. Моның өчен нәрсәнең яхшы, нәрсәнең яман булуын белергә кирәк. Һичшиксез, бала тәрбиясе, балалар язмышы хакында барлык кешеләр дә кайгыртырга тиеш, үзеңнеке генә түгел, башка балалар хакында да! Чөнки синең бик тырышып тәрбияләгән балаң иртәгә яманга иярмәс, яисә аннан зыян күрмәс дип кем гарантия бирә ала? Әйе, бүген диннәр мәдәниятен мәктәптә өйрәтә башлыйлар. Әмма тик аңа карап әти-әни өстеннән бурыч алынмый. Әти-әни үзенең һәм баласының калган намазы кадәр тәмугта газап чигәргә мөмкин, шуңа күрә без балаларыбызны намаз укырлык хәлгә китерергә бурычлыбыз. Балаларыбызга күркәм тәрбия биреп, оҗмахлы итәбезме, дөнья мәшәкате белән генә мавыгып, тәмуглы итәбезме – барысы да үзебездән тора. Бүген кешелек җәмгыятенең рухи кризис кичерүе, әчкечелек, наркомания, җинаятьчелекнең үсүе, кешеләрнең үз-үзләренә кул салулары үз вакытында аларга дин турында тиешле мәгълүмат бирелмәүдән килә. Шуны аңлау һәм яшьләргә тәрбия бирү юнәлешендә тырышлык күрсәтү безнең төп бурычларыбызның берсе.

Ә бүгенге көндә йөрәк җимешләренең киләчәгенә битараф булмыйча, үзләренә догачылар калдыру турында кайгыртып, балаларын әзерләп мәчеткә озаткан, аларга дини белем алырга мөмкинлекләр тудырган әти-әниләргә, әби-бабайларга; балаларының кызыксынуы сүнмәсен дип үзләре алар белән мәчеткә йөргән, тәм-томнар белән сыйлап торган хөрмәтле әбиләребезгә, укытучыларына зур рәхмәт сүзләре ирештерәсе килә.

# БӘХЕТЛЕ ГАИЛӘ НИГЕЗЛӘРЕ

**(Ахыры. Башы газетабызның 12нче санында)**

Хатын-кызлар күбрәк өйдә эшләгәч, ислам дине тыштагы эшләрне эшләргә мәҗбүр итми. Ир кеше өй эшләрендә дә хатынына булышырга тиеш. Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) дә хатыннарына өй эшләрендә булыша торган булган. Балаларны хатын-кыз тәрбияләсә дә, ислам дине аңа бу гамәлне бер үзенә генә башкарып чыгарга мәҗбүр итми. Бала тәрбиясе — хатын-кызның һәм ир-атның бурычы. Хатын-кыз күп вакытын бала белән үткәрсә дә, ир барлык гаилә әгъзаларының тәрбияле булулары өчен җавап бирүче кеше. Ир белән хатын бергәләп өйдә мөселман мохитен тудырырга тиешләр.

Мөселман гаиләләре үзләренең ныклыгы белән аерылып тора. Бу берничә фактор белән нигезләнгән. Беренчедән, диннән ерак булган кешеләрнең никахлары аңа кадәр үк җенси якынлык кылганлыклары белән аерылып тора, шуңа күрә мөселман гаиләсенең нигезендә гомумкешелек кыйммәтләре ята. Икенчедән, күп очракта мөселманнар ир-ат белән хатын-кыз арасындагы хакхокуклар белән килешәләр. Монда хезмәт бүленеше ачык итеп бирелгән, шуңа күрә күп кенә авырлыклар булмыйча кала.

Бер сүз белән генә әйткәндә, мөселман никахы Голливуд рухындагы хыялый союз гына түгел, ә ике кавемнең туганлашуына нигезләнгән. Әлбәттә гаиләдә төрле хәлләр булырга мөмкин. Ләкин теләсә-нинди каршылык мохитнең тәрбияви көчендә уңай якка хәл ителә, ә гаилә таркалу белән түгел. Мөселман никахы тотрыклы һәм тормышчан институт булырга тиеш.

Никахланырга кирәк дигәндә, бу егетнең биологик, социаль, матди, гражданлык ягыннан өлгергәнлеген аңлата.

Күпхатынлылык Аллаһ тарафыннан бер диндә дә тыелмый. Ислам дине 4 хатынга гына өйләнергә рөхсәт итә. Анысы да әле дүртесенә дә бертигез хакларын үти алса.

Мөхәммәд Пәйгамбәргә килсәк, ул бергә 25 ел торган Хәдичә исемле хатыны үлгәч кенә башка хатын-кызларга никахланган. Аларның бер-берсенә карата булган мөнәсәбәте–мөселман гаиләләре өчен зур үрнәк.

Исламда никах рухы — бер-береңне хөрмәт итү, изгелек, мәхәббәт рухы. Хатын-кыз ирен шатлык белән кайгыларны уртаклашучы, кирәк вакытта булышучы дусты итеп кабул итә. Ир үзенең хатынын тынычлыкны һәм рәхәтлекне булдыручы иптәше итеп күрә.

Алда зекер ителгәннәргә нәтиҗә ясап ир белән хатынга түбәндәге киңәшләр бирергә була. Алар гаиләдә гармония булдырырга ярдәм итәр.

**Беренче киңәш:** Тормышыбызда һәр гамәлне Аллаһ риза булсын дип эшләү, йөрәгебездә аңа карата олы ярату һәм итагать булдыру.

Чөнки гаилә схемасыннан Аллаһы Тәгаләне һәм аңа ышануны алып атсаң безнең тормышыбыз картоннан ясалган өй мисалында җимерeләчәк. Без тырышып гаилә тормышын төзәргә тырышачакбыз, әмма пазлылардан төзелгән рәсемдәй ул килеп чыкмас. Чөнки анда бердәнбер иң кирәкле фрагмент җитми торган булыр. Ул фрагментны табып кирәкле җиргә куюга сокландыргыч рәсем пәйда булачак. Гаилә тормышында да шулай. Чөнки Аллаһ кына чын мәгънәсендә гыйбадәткә, итагатькә, яратуга һәм хөрмәткә лаеклы. Ул гына безнең бөек хуҗабыз. Истә тотыйк-иң беренче урында Аллаһ булса гына гаиләбез нык, тотрыклы булачак.

**Икенче киңәш:** Гаиләдә иң мөһиме — иреңне ризалату. Аны кайгыртып, карап, күңелен күреп торырга кирәк. Әгәр синең белән ирең риза икән, димәк, Аллаһ та риза. Хатын ире кайтуга ашарга пешергән, өйне рәткә китергән, матур киенгән булырга тиеш. Ир хатынына карап ял итә. Хатын кеше матур сөйләшергә дә, тәмле пешерергә дә һ.б. күп әйберләрне белергә тиеш.

Хатын-кыз чиста, оялчан, тырыш, сабыр, акыллы булырга тиеш. Татар кызларына бу сыйфатлар элек-электән гаиләдә салынган. Элек-электән татарларда гаиләгә зур игътибар бирелгән. Бу аның гадәт-йолаларында ук күренә: ючылык, нәсел-нәсәп тикшерү, ярәштерү, киленне, кияүне эш белән сынап карау... Кызганыч, вакыт узу белән алар да югалып килә.

**Өченче киңәш:** Ирeңнең туганнары белән яхшы мөгамәләдә булу.

Иреңнең әти-әнисе, туган-тумачасы белән уртак тел табу — иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Бигрәк тә аның әнисенә игътибарлы, шәфкатьле булу ирең белән араларны җылы тоту өчен аеруча мөһим. Кечкенә генә бүләк тә, ягымлы сүз дә ирeңнең йөрәгенә май булып ятачак. Чөнки ир кеше өчен иң зур хак — ана хакын хаклау.

**Дүртенче киңәш:** Сабыр булу һәм юл бирә белү.

Бер караганда гаиләдә бәхетле булу рецепты бик җиңел һәм бик гади дә. Бәхет өчен бераз гына сабырлык, бер-береңне аңлау, йомшаклык кына да җитә. Кызганыч бүген без вактөяк мәсьәләләргә бирелеп, бер-беребезне аңларга теләмичә, бер-беребезгә юл куймыйча, тәкәбберләнеп, сабырлык һәм йомшаклыкны читтә калдырып гаилә мөнәсәбәтләрен челпәрәмә китерәбез. Аннан соң, буласы булгач, үкенгән булабыз, ачуыбызны басабыз. Әмма ясалган яралар озак төзәләләр.

**Бишенче киңәш:** Гаилә тормышын шөкер итеп яшәүгә нигезләү. Гаиләдә бәхетле булуны шулай ук Аллаһы Тәгаләгә шөкер итеп яшәү белән аңлатып була. Әгәр син Раббыбыз биргәнгә канәгать икән, аңа рәхмәтле икән, хатыныңнан яки иреңнән риза икән, димәк син бәхетле. Юк исә, син Аллаһының тәкъдиренә риза түгел. Шуны онытмаска кирәк: ир белән хатынның бергә кавышулары да, аларның бер-берсен яратулары да Раббыбызның тәкъдире.

**Алтынчы киңәш:** Гаиләдә бер-береңне аңлап сөйләшә һәм киңәшләшә белергә кирәк.

Әгәр без менә бу гади генә әйберләрне даими рәвештә үз тормышыбызда куллана башласак, гаиләбез тагын да ныгыр һәм ямьләнер иде. Кайбер гаиләләрдә бер-берләрен аңлар өчен, фикерләрен бер-берсенә җиткерер өчен “тәрҗемәче” ялларга кирәк. Ә кайбер гаиләдә хатын белән ир арасында элемтә гел юк дәрәҗәсендә. Социаль тикшеренүләр шуны күрсәтә: “Ирләрегез белән кичә ничә минут сөйләштегез”,-дигән сорауга хатыннарның 50%ы: “Бер минут та сөйләшмәдек”,-дип җавап биргән. Кызганыч, бүген чәй артында җылы сөйләшүләрне телевизор һәм компьютер алыштыра. Шул сәбәпле гаиләдә бер-береңне аңлау, элемтә кими.

**Җиденче киңәш:** Бер-береңне тыңлый белергә өйрәнү.

Гаиләдә сөйләшүгә карагандa тыңлый белү өстенрәк. Чөнки ул сезнең битараф түгеллегегезне, ирегезгә яки хатыныгызга карата ихтирамыгызны күрсәтә, аның фикерләренең аерым игътибарга лаек икәнлеген белдерә.

**Сигезенче киңәш:** Гафу сорый белү һәм гафу итү.

Уйлап карыйк әле: “Гафу ит мине”,-дигән сүзне без еш әйтәбезме. Кызганыч, гаиләдә ыгы-зыгы булган вакытында, савыт-саба шалтыраган мизгелләрдә без гафу сорау, сабыр итү турында түгел, ә бәлки ничек кенә күңелне катырак яралый торган сүзләрне әйтү турында уйланабыз. Чыккан тавыштан соң бер-береңә ачу тоту башлана, кайберләр атналар буе эндәшмичә йөриләр. Мондый алымнар яңа конфликтка нигез сала.

Алдагы зекер ителгәннәргә нәтиҗә ясап шуны ассызыклап әйтергә була: дөреслектә, гаилә – үзенә бер төрле дәүләт ул. Аның үз президенты, премьер-министры була. Гаиләдә, илдәге кебек үк һәр кешенең үз вазыйфасы бар: президентның үзенеке, премьер-министрның үзенеке. Гаиләнең үз законы, уставы, үз икътисады, теле, социаль мәсьәләләре, проблемалары бар. Онытмыйк: һәр кеше үз эшен белеп, җиренә җиткереп башкарганда гына, гаиләдә гармония була.

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН әзерләде.**

# ДӨНЬЯ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## КИЛӘСЕ ЕЛДА «КОЛ ШӘРИФ»НЕҢ 130 ЕЛЛЫГЫ

**Күпләр «Кол Шәриф» исемендәге мәчетнең Казанда гына булмавын белмидер дә әле.** Шушы ук исемдәге гыйбадәтханә Оренбург өлкәсенең Әсәкәй районындагы Иске Колшәриф авылында да бар.

Иске Колшәриф авылындагы мәчет 1883 елда төзелгән. Киләсе 2013 елда авыл халкы бу гыйбадәтханәнең 130 еллыгын билгеләп узарга җыена. Җомга намазлары һәм гаетләрдә мәчет намаз укучылар белән тулы була.

«Кол Шәриф» мәчетенең имамы Мөхәммәт хәзрәт Гаделгәрәев инде берничә дистә еллар буена бу мәхәлләнең рухи җитәкчесе булып тора. Аңа күптән түгел 83 яшь тулды, дип хәбәр итте Россия мөселманнарының берләштерелгән Ислам үзәге оешмасы хезмәткәре.

## «ТАТАРСТАННЫҢ ИСЛАМ МӘГАРИФЕ» ИСЕМЛЕ ЯҢА САЙТ БАРЛЫККА КИЛДЕ

**Интернет челтәрендә «Татарстанның Ислам мәгарифе» исемендәге яңа сайт эшли башлады.**

Сайт Үзәкләшкән дини оешма –Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Мәгариф һәм фән бүлеге эшчәнлеген яктыртачак. Биредә уку программалары урнаштырылган, шулай ук Татарстандагы мөселман уку йортлары турында киңәйтелгән мәгълүмат бирелгән. Тиздән әлеге Интернет-сайтта Татарстанда ислам мәгарифе өлкәсендәге яңалыклар, кызыклы язмалар эленәчәк. Сайтның адресы: magaryf.ru

## ТАТАРСТАНДА ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАС ЕЛЫ БАШЛАНДЫ

**20 февральдә Казанда Русия тарихы елы һәм Татарстанда тарихи-мәдәни мирас елының тантаналы ачылышы булды.**

Әлеге чара Татарстан мәдәният министрлыгының агымдагы елда «Үткәннәргә кайту, тамырларга борылу» дигән исем астында уздырырга планлаштырган чараларның башлангычы дип әйтелде.

**Чыганак: “Думрт.ру”**

# «Сәлам, дөнья» - хәләл медиа челтәре

**Киләсе изге Рамазан аенда халыкара беренче мөселман социаль челтәре — «SALAMWORLD» эшли башлаячак.**

Якын киләчәктә интернетта мөселман дөньясының үз социаль челтәре булачак. Ул «SALAMWORLD» ягъни «Сәлам, дөнья» дип атала. Аның агымдагы елның июль аенда эшли башалавы көтелә. Күптән түгел Истанбулның Кемпинский кунакханәсендә әлеге проектны таныту буенча глобаль саммит үткәрелде. Җыенга дөньяның 40 иленнән эшкуарлар, сәясәтчеләр, дипломатлар, дөньякүләм танылган журналистлар, компьютер белгечләре, программистлар катнашты. «SALAMWORLD» проектының инициаторы һәм мөдирләр шурасы рәисе, Россия мөфтиләре шурасының Ислам мәдәнияте үзәге җитәкчесе Абдулвахит Ниязов чыгышында саммитны оештыру максатының Ислам дөньясында күренекле шәхесләрнең «SALAMWORLD» проекты хакында туган сорауларга җавап бирүләрен булдырудан гыйбарәт икәнлеген әйтте. «»SALAMWORLD« социаль челтәре Ислам өммәте белән дөньяның башка төркемнәре арасында күпер булачак. Бу проектны тормышка ашырганда алдынгы технологияләр кулланылачак. «SALAMWORLD» дөньяда Ислам мәдәнияте һәм мирасын, рухи байлыкларын танытуга юнәлтелгән элемтә платформасы булып хезмәт итәчәк»,–диде ул. Ниязовның әйтүенчә, «SALAMWORLD»ны кору фикере узган елның җәй көнендә Казахстанда үткән бер җыенда барлыкка килгән. Аның бу омтылышын башкалар да куәтләп алган. Нәтиҗәдә, 4 аеры илнең 7 эшкуары проектны тормышка ашырырга керешә. Проектның авторы һәм җитәкчесе, чыгышы белән Омск татары Абдулвахит Ниязов белдергәнчә, «SALAMWORLD» — Ислам дөньясының фидакарьләре тарафыннан оештырылган хәләл аралашу платформасы. «SALAMWORLD» «вконтакте», «facebook», «twitter» кебек социаль челтәрләргә көндәш булырга җыенмый, аның башкалардан шактый аермасы булачак. Беренчедән, ул җир йөзендәге барлык мөселманнарның уртак аралашу аланы булып торачак. Биредә адәм баласының яшәешенә, тәрбиясенә, сәламәтлегенә хәрам булган һәр нәрсә тыелачак. Әйтик, шәрә хатын-кыз рәсемнәренә, порнокүренешләргә, оятсыз сүзләргә урын бирелмәячәк. Ислам өммәтенә адресланган булуына карамастан, башка диннәр яки динсезләр төркеме белән аралашу чикләнмәгән. Киресенчә, бу платформадан дөньяның барлык кешеләре файдалана алачак. Шунлыктан аны «Тынычлык йорты» дип тә атарга мөмкин. Икенчедән, «SALAMWORLD» медиачелтәрендә, башкалардан аермалы буларак, Ислам алтын динары нигезендә хәләл интернет-кибет эшләячәк. Шулай ук on-line Ислам китапханәсе, һәр төрле мәсьәләдә ярдәмгә әзер киңәш үзәге дә «SALAMWORLD» кулланучыларының хезмәтендә булачак. Шул исәптән, төрле уеннар, башваткычлар да читтә калмаячак. Бу социаль челтәр аркылы Ислам диненең бөтен үзенчәлекләре белән танышу мөмкинлеге бирелә. Хәтта on-line фәтва да булачак.

«SALAMWORLD»ның башлангычта төрек, рус, инглиз, гарәп, француз һәм фарсы телләрендә эшләве каралган, тора бара азәрбайҗан, казах, үзбәк, урду, кытай, көрт, бенгал, малай кебек 15 телдә аралашу мөмкинлеге булдырылачак дип хәбәр итте “Татар-информ”.

# Догалар ник кабул булмый?

Рухи остаз, Ибраһим ибн Әдһәм Басра шәһәренең урамнарыннан барган вакытта Басрада яшәүче кешеләр җыелып, хәзрәттән:

–Әй, хәзрәт, без Аллаһы Тәгаләдән сорыйбыз, әмма ул безгә җавап кайтармый. Нигә догаларыбыз кабул булмый икән?,–дип сорадылар.

–Әй, Басра шәһәрендә яшәүче кешеләр, ничек Аллаһы Тәгалә догаларыгызга җавап бирсен? Сезнең күңелләрегез, йөрәкләрегез үле бит. Күңелләрегезнең, йөрәкләрегезнең үлүендә ун төрле сәбәп бар. Беренчесе, без Аллаһы Тәгаләгә иман китердек, аны таныдык, дип әйтәсез. Коръәнне бик матур итеп укыйсыз, әмма Коръән өйрәткәнчә эшләмисез. Аллаһының илчесе, Мөхәммәтне (г.с.в.) сөябез, хөрмәт итәбез, дип әйтәсез, әмма ул күрсәткән юлдан читләшеп йөрисез. Шайтан–безнең дошманыбыз, дип сөйлисез, әмма эшләгән эшләрегезгә карасаң, аны үзегезгә дус иткәнсез. Җәннәткә керергә телибез, дип аңлатмалар бирәсез, әмма анда эләгер өчен берниндi тырышлык куймыйсыз. Җәһәннәм утыннан котылырга кирәк, дип кычкырасыз, әмма үзегез анда илтә торган юлларда йөрисез. Үлем тиздән килер, безне алып китәр, дип сөйләгән буласыз, әмма ул үлемгә бер дә әзерлек күрсәтмисез. Кешеләрне тикшереп гомерегезне уздырасыз, әмма үзегезнең кимчелекләр чокырына төшеп, батканыгызны сизмисез. Сезнең арагызда үлгән кешеләрне, кабергә илтеп, күмеп куясыз, әмма шуннан гыйбрәт ала белмисез. Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрен иртә, кич ашап торасыз, бар өстенә «юк», дип Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтә белмисез. Әй, Басрада яшәүче кешеләр, сез бит тере булып күренсәгез дә, анда-монда селкенеп йөрсәгез дә, Аллаһы Тәгалә каршысында мәетләр кебек яшисез. Мәетләр Аллаһы Тәгаләдән нәрсә сорый алсыннар? Берәр әйбер сорасалар да, Аллаһы Тәгалә мәетләргә ничек җавап бирсен?! Догагыз кабул булуны теләсәгез, күңелләрегезне терелтеп, мәет булудан үзегезне коткарыгыз,–диде.

# “Нәсыйхәт”–җанга сихәт

**–Безнең районда да мөселманнар проблемаларын яктырткан газета чыга башлауга бер ел. Бу газета бик көтелгән басма иде.**

**ГӨЛКӘЙ ӘҺЛИУЛЛИНА:** Казаннан “Ислам–инфо” укып, Чаллыдан “Ислам нуры” алдырып, кайчан үзебездә чыккан газета күрербез дип сөйләшә идек. Әлхәмдүлилләһи шөкер, ул газета бар. Һәм аны бер ел укыдык. Аны чыгаруга күп көч куйган Габдрахман хәзрәткә, Эльвира, Алсу, Фирая ханымнарга Аллаһының рәхмәте булсын, аларга Аллаһ исәнлек, иминлек бирсен һәм бу эшләреннән тайпылырга язмасын. Газетаны көтеп алабыз, укыйбыз, кайчак кабат кайта-кайта укыйбыз. Берәр сораугa җавап эзли башласак газетадан табабыз. Иң охшаган рубрикалар – сорауларга җаваплар, мөселман дөньясы яңалыклары һәм район мөселманнары яңалыклары, викториналар. Аллаһы Тәгалә ярдәме белән газета чыгу дәвамлы булсын, укучылары күп һәм актив булсын дигән теләктә калам.

**РӘСИМӘ РӘХИМУЛЛИНА:** –Мамадыш мәдрәсәсендә чыгып килүче “Нәсыйхәт” газетасы миңа бик ошый. Габдрахман хәзрәтнең күңелләргә шифа бирә торган Коръәни-Кәрим аятьләре һәм пәйгамбәребезнең хәдисләре белән үрелеп барган мәкаләләре белән күңелебезне тәрбиялибез. Эльвира абыстайның нәсыйхәтле мәкаләләре бик ошый. Аларга зур уңышлар телим. Газета битләрендә дәү әни, әбиләр турында, аларның күркәм әхлаклары хакында укырга теләр идем.

**ӘЛФИЯ ЗАРИПОВА:** –“Нәсыйхәт” газетасы бик мәгънәле, эчтәлекле газета булып чыкты. Без аның һәрбер санын көтеп алабыз. Гаилә, яшьләр темасын киң яктыртасыз. Алга таба да сезгә иҗади уңышлар, сәламәтлек, гаилә бәхете телибез. Мәдрәсәдә укулар гөрләп барсын, без бик теләп йөргән кебек дәресләргә барлык Мамадыш шәһәре халкы да теләп йөрсәләр иде. Алдагы саннарында викторина сораулары бирә башлаган идегез, күп китаплар укып, өйдә җаваплар табып, икенче санын көтеп алып, җавапларны чагыштыра идек. Газетагызда викторина рубрикасын дәвам итсәгез, тагын да кызыклы булыр.

**ӘХМӘДИЕВА РЕЗИДА:** –Балага бер яшь тулганда аның адымнары ныгый, ул дөнья белән таныша, кеше арасына керә. Безнең “Нәсыйхәт” газетасына да бер яшь. Яшь булуына карамастан, газетабыз киң эчтәлекле, күп мәгълүматны эченә алган. Газета чыгаручыларыбыз бик кирәкле, савaплы эш башкаралар. Аларга Аллаһ Раббыбыз саулык–сәламәтлек, уңышлар, бәхет-шатлык, гаиләләренә иминлек насыйп итсен. Газетабызның адымнары нык булсын, башка массакүләм газеталары арасында алдынгылардан булса иде.

**РӘМЗИЯ БИКТАҺИРОВА:** –Мәдрәсә каршында чыгып килүче, Нәсыйхәт” газетасын көтеп алабыз һәм яратып укыйбыз. Газета тирән эчтәлекле, монда үзеңне кызыксындырган күп сорауларга җавап табарга була. Бигрәк тә Габдрахман хәзрәт Хәбибуллинның “Дин–яшәү рәвеше” рубрикасында бирелгән язмалары, “Сорау-җавап” рубрикасы охшый. “Дөнья яңалыклары” рубрикасы кечкенә форматлы газетада зур урын алып тора. Газетаны бер яшь тулган көне белән котлыйм, озын гомерле булсын, әбүнәчеләре көннән-көн артсын.

**ВЕНЕРА ЯРУЛЛИНА:** –“Нәсыйхәт” – хәзерге вакытта актуаль булган темаларны яктыртып чыгучы газета. Яшь буыннарга да, өлкәннәр өчен дә дини мәгълүмат чыганагы булып тора. Киләчәктә дә “Нәсыйхәт” газетасы җәмгыятькә файда китереп, динебезне таратуда хезмәт итәр дигән өметтә калам.

**Әңгәмәне ЭЛЬВИРА ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде**

# Сорау-җавап

**Хәзер яшьләр арасында интернет буенча никах турында күп бәхәсләр бара. Ул рөхсәт ителәме, юкмы? Рөхсәт ителсә, нинди очракларда аңа мөрәҗәгать кылырга була?**

**МӨСЛИМӘ**

–Бу хакта уйлар төрле булырга мөмкин дигән фикерләр белән килешәм. Ник дигәндә, интернетка кагылышлы мәсьәләләрне Коръәндә дә, сөннәттә дә табып булмый. Ә менә никахның исламда җитди вакыйга икәнлегенә аятьләр һәм хәдисләр күп. Ислам күзлегеннән чыгып караганда, никах бөтен гомер буена укыла. Ул Аллаһ каршында зур җаваплылык, аның өчен кыямәт көнендә җавап бирәсе була. Биредә ата-аналарның фатихасын аласы бар, шаһитләрнең катнашуы мөһим, кияү кәләшкә кыйммәтле туй бүләге бирә, никах укыту турында халыкка җиткерелә һәм башкалар. Боларның барысы да кешеләрдә җаваплылык уята. Кеше үзенең табигате буенча йомшак. Бу хакта изге китапта да әйтелә. Ислам таләпләре һәм милли гореф-гадәтләр кешегә көчәергә булыша. Болар гаилә төзү мәсьәләсенә дә кагыла. Интернет аша никахлашуны мин җиңел акыл белән эшләнгән гамәл дип саныйм. Алар хәзерге заманның яшерен һәм гражданлык никахы белән яшәүне хәтерләтә. Кайберәүләр сөяркәләре белән зина кылуны бу икенче, өченче, дүртенче хатыным дип аңлата. Бүгенге көндә җәмгыятьтә әдәп-әхлак популяр булмаганда, мин интернет аша никахлашуны зина кылуга якын, ягъни гөнаһлы гамәл дип атар идем.

**Җавап umma.ru дан алынды**

**Намазны кайсы вакытта уку хәерлерәк? Бу гыйбадәтне азан әйткәч тә кылырга кирәкме, әллә кайбер мәчетләрдәге кебек, бераз көтеп торырга дә ярыймы? Гарәп илләрендә намазны башка вакыттарак укулары турында да ишеткәнем бар.**

**ТАҺИР КӘРИМУЛЛИН, КАЗАН**

–Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗиим. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Һәрбер намазны вакыты керү белән уку хәерлерәк» – дигән. Дөрес, монда бер аерым искәрмә кебек нәрсә дә бар. Әйтик, ястү намазы мәчетләрдә вакыты керү белән укыла. Ләкин Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Ястүне кичектереп укырга мөмкинлегегез бар икән, кичектерегез. Моның әҗер-савабы күбрәк», – дигән. Ә инде калган намазларны, бигрәк тә ахшамны, вакыты керү белән үк уку хәерлерәк, чөнки аның вакыты кыска. Башка намазларны да үз вакытында, ягъни вакыты керү белән уку саваплырак. Намаз гарәп илләрендә шулай ук вакытында укыла. Анда фәкать азан белән камәт арасында берникадәр ара калдырыла. Бу мәчеткә күбрәк халык җыелсын өчен шулай эшләнә. Дөрес, аларда икенде намазы безнең Әбү-Хәнифә мәзһәбендәгеләргә караганда бераз алданрак укыла. Ә бездә, Татарстанда, намазларны азан әйтелгәч тә уку гадәткә кергән.

**Җавап tatar-islam.ru сайтыннан алынды**


# БЕЛДЕРҮЛӘР

*Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.
*Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)
*Мәдрәсә базасында таныштыру бүлеге эшли. Тел. 89625504168, 89372991485
Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мөрәсимнәрне үткәрү. Мамадыш мәдрәсәсе, М.Җәлил ур 8/28), тел: 89172802391
*Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз.
*Мамадыш мәдрәсәсе фәкыйрь-мескеннәргә, ятим балаларга тарату өчен кулланылган киемнәр кабул итә.
*Мәдрәсә базасында Ислам диненә караган сорауларга җавап бирү хезмәте
*Мәдрәсә “Бер айда намаз укырга өйрән” түгәрәгенә укучылар җыя, Белешмәләр өчен телефон: 89172802391

# Таныш булыйк: Әлфирә Хаҗиева



Мөхәммәд пәйгамбәр турында шигырь конкурсы җиңүчесе Әлфирә Хаҗиевага бүләк тапшыру мизгеле.

**–Кайчан шигырьләр яза башладыгыз? Моңа сезне нәрсә этәрде?**

–2011 нче елның 12 нче февралендә кадерле әнием ахирәт тормышына күчте. Әнием белән аерылуны бик тә авыр кичердем. Кайгы-хисләрем күңелемә генә сыя алмыйча шигырь юлларына күчте. Аллаһы Тәгалә миңа шулай җиңеллек бирде.

**–Сезнең шигырьләрегездә төрле тормыш аспектлары яктыртыла. Дини темага шигырьләрне язу авырмы?**

–Шигырь юлларын күңелгә Аллаһы Тәгалә сала дип уйлыйм мин. Теманы дөрес яктырту өчен дини белем булырга тиеш. Дин ул–безнең өчен китерелгән, язылган, канун. Аны беркемнең дә үзгәртергә дә, бозып күрсәтергә дә хакы юк.

**–Дин юлына кереп китәргә нәрсә сәбәпче булды?**

–Тормыш иптәшемнең, аннан соң 9 нчы сыйныфта укучы улым Гумәрнең намазга басуы минем өчен зур куаныч булды. 2010нчы елда, тормыш иптәшем Марсель хаҗ кылган вакытта Аллаһы Тәгалә күңелемә “Һәр кешенең кылган гамәлләре, укыган намазлары үзе өчен. Мин алар өчен куанып кына калырга тиеш түгел, үземә тиешле бурычларны үтәргә тиеш”,–дигән уй салды һәм мин намазга бастым.

**–Кешеләрдә нинди сыйфатларны хөрмәт итәсез?**

–Гаделлек һәм гадилекне.

**–Укучыларыбызга нинди теләкләрегез бар?**

–Тормыш ул–озын юл. Шушы юлны дөрес үтеп, барасы урыныбыз хәерле булсын өчен, без Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәргә, тыйлганнарыннан тыелырга тиеш. Аллаһы Тәгалә үзенең барча иманлы колларына Үзенә якынаерга хәерле ярдәмен насыйп итсә иде !

**Әңгәмәне ЭЛЬВИРА ХӘБИБУЛЛИНА үткәрде.**

## Мөхәммәд рәсүлуллаһ

Лә иләһә иллә Аллаһ
Мөхәммәд рәсүлуллаһ–
Мөэминнәрнең хуҗасы.
Ятим, көтүче, хезмәтче–
Таныш дөнья нужасы.
Аллаһы Тәгаләне тану–
Мәгърифәт малының башы.
Гыйлемлелек–юлдашы.
Аллаһыны зекер итү–
Пакь йөрәге йомышы.
Тулган ай кебек йөзе,
Җәүһәрдер һәрбер сүзе.
Елмаюдыр–көлүе,
Ике нур кебек күзе.
Балкыган һәрчак үзе.
Дин юлына сарыф иткән,
Бирелгән барлык көчен.
Вәхи белән юл күрсәткән,
Ныклы иманга чакырган,
Кайгырган өммәте өчен.
Үрнәк булган һәр эше.
Бер үзенә бирелгәндер
Кырык пәйгамбәр көче.
Дөньялыктан күчкән чакта
Тулган алтмыш өч яше.
“Лә иләһә иллә Аллаһ,
Мөхәммәд рәсүлуллаһ”
Әйтә мөэмин шәһадәт.
Аллаһының илчесеннән
Өмет итә шәфәгать.

## Аклык

Ни өчен кар яшел түгел,
Я булмаса кызыл
һәм сары?!
Һәр сорауга җавап
табып була,
Уйландырды әле ак кары.
Көзне кышка бәйләп
ява ак кар,
Туй күлмәге кия җиребез.
Бу фасылда
дөнья чистарына,
Кар астында кала чүбебез.
Кирәк чакта
калын юрган була,
Бер мизгелдә суга әйләнә.
Басу- кырны
кар сулары юа,
Елга, күлләр шулчак туена.
Шушы гади, ләкин
серле ак кар,
Көнгә, төнгә бирә яктылык.
Күңелләрне, илаһи
аклык кебек,
Каралтмыйча, пакъ
көе саклыйк.
Нинди олы могҗизага ия,
Аңлый алсак, шушы
бер кары.
Кыш җиткәчтен ак
кар булып ява.

## Гүзәл туган як

Елга буе: каен кызлары
Көмеш бәстән күлмәк
кигәннәр.
Тал егетләреннән оялып,
Бөдрә башын аска игәннәр.
Текә ярның дәвамы булып,
Биек калкулыклар
Су тамчысы үзе нибары!
сузылган.
Норма авылын ышыклап,
төреп,
Рәт-рәт булып
нарат тезелгән.
Авылымның эшчән,
тырыш халкы
Шифа ала нарат исеннән.
Туган якның гүзәл табигате,
Чыкмый минем
һич тә исемнән.

**ӘЛФИРӘ ХАҖИЕВА**



**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**